УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

О проверке достоверности и полноты сведений, представляемых гражданами, претендующими на замещение должностей муниципальной службы в Республике Татарстан, и муниципальными служащими в Республике Татарстан, и соблюдения муниципальными служащими в Республике Татарстан требований к служебному поведению

В соответствии с Федеральным законом от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции», частью 6 статьи 15 Федерального закона от 2 марта 2007 года № 25-ФЗ «О муниципальной службе в Российской Федерации», частью 8 статьи 18 Кодекса Республики Татарстан о муниципальной службе, с учетом положений Указа Президента Российской Федерации от 21 сентября 2009 года № 1065 «О проверке достоверности и полноты сведений, представляемых гражданами, претендующими на замещение должностей федеральной государственной службы, и федеральными государственными служащими, и соблюдения федеральными государственными служащими требований к служебному поведению», Указа Президента Республики Татарстан от 1 ноября 2010 года № УП-711 «О проверке достоверности и полноты сведений, представляемых гражданами, претендующими на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, и государственными гражданскими служащими Республики Татарстан, и соблюдения государственными гражданскими служащими Республики Татарстан требований к служебному поведению» **постановляю:**

1. Утвердить прилагаемое Положение о проверке достоверности и полноты сведений, представляемых гражданами, претендующими на замещение должностей муниципальной службы в Республике Татарстан, и муниципальными служащими в Республике Татарстан, и соблюдения муниципальными служащими в Республике Татарстан требований к служебному поведению.

2. Органам местного самоуправления в Республике Татарстан привести свои муниципальные правовые акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, необходимые для его реализации.

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
02 февраля 2015 года
№ УП-71

Утверждено
Указом Президента
Республики Татарстан

от «02» февраля 2015 года

№ УП - 71

Положение
о проверке достоверности и полноты сведений, представляемых гражданами, претендующими на замещение должностей муниципальной службы в Республике Татарстан, и муниципальными служащими в Республике Татарстан, и соблюдения муниципальными служащими в Республике Татарстан требований к служебному поведению

1. Настоящим Положением определяется порядок осуществления проверки:

а) достоверности и полноты сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленных гражданами, претендующими на замещение должностей муниципальной службы в Республике Татарстан, включенных в перечни, установленные муниципальными правовыми актами (далее – граждане), на отчетную дату;

б) достоверности и полноты сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представляемых муниципальными служащими в Республике Татарстан, замещающими должности муниципальной службы в Республике Татарстан, включенные в перечни, установленные муниципальными правовыми актами (далее – муниципальные служащие), за отчетный период и за два года, предшествующие отчетному периоду;

в) достоверности и полноты сведений, представленных гражданами при поступлении на муниципальную службу в Республике Татарстан в соответствии с нормативными правовыми актами Российской Федерации (далее – сведения, представляемые гражданами в соответствии с нормативными правовыми актами Российской Федерации);

г) соблюдения муниципальными служащими в течение трех лет, предшествующих поступлению информации, явившейся основанием для осуществления проверки, предусмотренной настоящим подпунктом, ограничений и запретов, требований о предотвращении или об урегулировании конфликта интересов, исполнения ими обязанностей, установленных Федеральным законом от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции» и другими нормативными правовыми

актами Российской Федерации (далее – требования к служебному поведению).

2. Проверка, предусмотренная подпунктами «в» и «г» пункта 1 настоящего Положения, осуществляется соответственно в отношении граждан, претендующих на замещение любой должности муниципальной службы в Республике Татарстан (далее – должность муниципальной службы), и муниципальных служащих, замещающих любую должность муниципальной службы.

3. Проверка достоверности и полноты сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представляемых муниципальным служащим, замещающим должность муниципальной службы, не предусмотренную перечнем должностей, установленным муниципальным правовым актом, и претендующим на замещение должности муниципальной службы, предусмотренной этим перечнем должностей, осуществляется в порядке, установленном настоящим Положением для проверки сведений, представляемых гражданами в соответствии с нормативными правовыми актами Российской Федерации.

4. Проверка, предусмотренная пунктом 1 настоящего Положения, осуществляется по решению представителя нанимателя (работодателя) подразделением кадровой службы соответствующего муниципального органа по профилактике коррупционных и иных правонарушений (должностным лицом указанного органа, ответственным за работу по профилактике коррупционных и иных правонарушений) (далее – подразделение (должностное лицо), уполномоченное на осуществление проверки).

Решение принимается отдельно в отношении каждого гражданина или муниципального служащего и оформляется в письменной форме.

5. Основанием для проведения проверки, предусмотренной пунктом 1 настоящего Положения, является достаточная информация, представленная в письменном виде:

а) правоохранительными органами, иными государственными органами, органами местного самоуправления и их должностными лицами;

б) работниками подразделений кадровых служб муниципальных органов по профилактике коррупционных и иных правонарушений либо должностными лицами указанных органов, ответственными за работу по профилактике коррупционных и иных правонарушений;

в) региональными или местными отделениями политических партий, а также зарегистрированными в соответствии с законом региональными общественными объединениями, не являющимися политическими партиями;

г) общественным советом, созданным в соответствующем муниципальном образовании;

д) средствами массовой информации.

6. Информация анонимного характера не может служить основанием для проверки.

7. До проведения проверки подразделение (должностное лицо), уполномоченное на осуществление проверки, должно затребовать от

муниципального служащего объяснение в письменной форме. Если по истечении двух рабочих дней указанное объяснение муниципальным служащим не представлено, то составляется соответствующий акт. Непредставление муниципальным служащим объяснения не является препятствием для проведения проверки.

8. Проверка осуществляется в срок, не превышающий 60 дней со дня принятия решения о ее проведении. Срок проверки может быть продлен до 90 дней лицом, принявшим решение о ее проведении.

9. Подразделение (должностное лицо), уполномоченное на осуществление проверки, проводит проверку:

а) самостоятельно;

б) путем внесения в порядке, установленном пунктом 13 настоящего Положения, предложений о направлении запроса в федеральные органы исполнительной власти, уполномоченные на осуществление оперативно-розыскной деятельности, в соответствии с частью третьей статьи 7 Федерального закона от 12 августа 1995 года № 144-ФЗ «Об оперативно-розыскной деятельности».

10. При осуществлении проверки, предусмотренной подпунктом «а» пункта 9 настоящего Положения, подразделение (должностное лицо), уполномоченное на осуществление проверки, вправе:

а) проводить беседу с гражданином или муниципальным служащим;

б) изучать представленные гражданином или муниципальным служащим сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера и дополнительные материалы;

в) получать от гражданина или муниципального служащего пояснения по представленным им сведениям о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера и материалам;

г) направлять в установленном порядке запрос (кроме запросов, касающихся осуществления оперативно-розыскной деятельности или ее результатов, запросов в кредитные организации, налоговые органы Российской Федерации и органы, осуществляющие государственную регистрацию прав на недвижимое имущество и сделок с ним) в органы прокуратуры Российской Федерации, иные федеральные государственные органы, государственные органы Республики Татарстан, государственные органы субъектов Российской Федерации, территориальные органы федеральных государственных органов, органы местного самоуправления, на предприятия, в учреждения, организации и общественные объединения (далее – государственные органы и организации) об имеющихся у них сведениях: о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера гражданина или муниципального служащего, его супруги (супруга) и несовершеннолетних детей; о достоверности и полноте сведений, представленных гражданином в соответствии с нормативными правовыми актами Российской Федерации; о соблюдении муниципальным служащим требований к служебному поведению;

д) наводить справки у физических лиц и получать от них информацию с их согласия;

е) осуществлять анализ сведений, представленных гражданином или муниципальным служащим в соответствии с законодательством Российской Федерации о противодействии коррупции.

11. В запросе, предусмотренном подпунктом «г» пункта 10 настоящего Положения, указываются:

а) фамилия, имя, отчество руководителя государственного органа или организации, в которые направляется запрос;

б) нормативный правовой акт, на основании которого направляется запрос;

в) фамилия, имя, отчество, дата и место рождения, место регистрации, жительства и (или) пребывания, должность и место работы (службы), вид и реквизиты документа, удостоверяющего личность, гражданина или муниципального служащего, его супруги (супруга) и несовершеннолетних детей, сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера которых проверяются, гражданина, представившего сведения в соответствии с нормативными правовыми актами Российской Федерации, полнота и достоверность которых проверяются, либо муниципального служащего, в отношении которого имеются сведения о несоблюдении им требований к служебному поведению;

г) содержание и объем сведений, подлежащих проверке;

д) срок представления запрашиваемых сведений;

е) фамилия, инициалы и номер телефона муниципального служащего, подготовившего запрос;

ж) идентификационный номер налогоплательщика (в случае направления запроса в налоговые органы Российской Федерации);

з) другие необходимые сведения.

12. Запросы о представлении сведений, составляющих банковскую, налоговую или иную охраняемую законом тайну, запросы в правоохранительные органы о проведении оперативно-розыскных мероприятий в отношении граждан и муниципальных служащих, их супруг (супругов) и несовершеннолетних детей направляются Президентом Республики Татарстан в порядке, определяемом нормативными правовыми актами Российской Федерации.

13. В случае если при проведении проверки, предусмотренной пунктом 1 настоящего Положения, возникает необходимость направления запросов, указанных в пункте 12 настоящего Положения, глава соответствующего муниципального района (городского округа) Республики Татарстан вносит предложение Президенту Республики Татарстан. К указанному предложению прикладывается проект соответствующего запроса в виде проекта письма Президента Республики Татарстан, в котором отражаются сведения, предусмотренные пунктом 11 настоящего Положения.

В случае необходимости проведения оперативно-розыскных мероприятий в проекте письма Президента Республики Татарстан также

указываются сведения, послужившие основанием для проверки, государственные органы и организации, в которые направлялись (направлены) запросы, и вопросы, которые в них ставились, а также дается ссылка на соответствующие положения Федерального закона от 12 августа 1995 года № 144-ФЗ «Об оперативно-розыскной деятельности».

Предложение о направлении запросов, указанных в пункте 12 настоящего Положения, готовится подразделением (должностным лицом), уполномоченным на осуществление проверки, и направляется главе соответствующего муниципального района (городского округа) Республики Татарстан представителем нанимателя (работодателем).

14. Руководители государственных органов и организаций, в адрес которых поступил запрос, обязаны организовать исполнение запроса в порядке и сроки, установленные федеральными законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, и представить запрашиваемую информацию.

15. Подразделение (должностное лицо), уполномоченное на осуществление проверки, обеспечивает:

а) уведомление в письменной форме муниципального служащего о начале в отношении его проверки и разъяснение ему содержания подпункта «б» настоящего пункта – в течение двух рабочих дней со дня получения соответствующего решения;

б) проведение в случае обращения муниципального служащего беседы с ним, в ходе которой он должен быть проинформирован о том, какие сведения, представляемые им в соответствии с настоящим Положением, и соблюдение каких требований к служебному поведению подлежат проверке, - в течение семи рабочих дней со дня обращения муниципального служащего, а при наличии уважительной причины – в срок, согласованный с муниципальным служащим.

16. По окончании проверки подразделение (должностное лицо), уполномоченное на осуществление проверки, обязано ознакомить муниципального служащего с результатами проверки с соблюдением законодательства Российской Федерации о государственной тайне.

17. Муниципальный служащий вправе:

а) давать пояснения в письменной форме: в ходе проверки; по вопросам, указанным в подпункте «б» пункта 15 настоящего Положения; по результатам проверки;

б) представлять дополнительные материалы и давать по ним пояснения в письменной форме;

в) обращаться в подразделение (к должностному лицу), уполномоченное на осуществление проверки, с подлежащим удовлетворению ходатайством о проведении с ним беседы по вопросам, указанным в подпункте «б» пункта 15 настоящего Положения.

18. Пояснения, указанные в пункте 17 настоящего Положения, приобщаются к материалам проверки.

19. На период проведения проверки муниципальный служащий может быть отстранен от замещаемой должности муниципальной службы на срок, не превышающий 60 дней со дня принятия решения о ее проведении. Указанный срок может быть продлен до 90 дней лицом, принявшим решение о проведении проверки.

На период отстранения муниципального служащего от замещаемой должности муниципальной службы денежное содержание по замещаемой им должности сохраняется.

20. Подразделение (должностное лицо), уполномоченное на осуществление проверки, представляет представителю нанимателя (работодателю) доклад о результатах проведенной проверки. При этом в докладе должно содержаться одно из следующих предложений:

а) о назначении гражданина на должность муниципальной службы;

б) об отказе гражданину в назначении на должность муниципальной службы;

в) об отсутствии оснований для применения к муниципальному служащему мер юридической ответственности;

г) о применении к муниципальному служащему мер юридической ответственности;

д) о представлении материалов проверки в соответствующую комиссию по соблюдению требований к служебному поведению муниципальных служащих и урегулированию конфликта интересов.

21. Сведения о результатах проверки с письменного согласия лица, принявшего решение о ее проведении, предоставляются подразделением (должностным лицом), уполномоченным на осуществление проверки, с одновременным уведомлением об этом гражданина или муниципального служащего, в отношении которых проводилась проверка, правоохранительным органам, иным государственным органам, органам местного самоуправления и их должностным лицам, региональным или местным отделениям политических партий, зарегистрированным в соответствии с законом региональным общественным объединениям, не являющимся политическими партиями, общественному совету, созданному в соответствующем муниципальном образовании, предоставившим информацию, явившуюся основанием для проведения проверки, с соблюдением законодательства Российской Федерации о персональных данных и государственной тайне.

22. При установлении в ходе проверки обстоятельств, свидетельствующих о наличии признаков преступления или административного правонарушения, материалы об этом представляются в государственные органы в соответствии с их компетенцией.

23. Должностное лицо, уполномоченное назначать гражданина на должность муниципальной службы или назначившее муниципального служащего на должность муниципальной службы, рассмотрев доклад и соответствующее предложение, указанные в пункте 20 настоящего Положения, принимает одно из следующих решений:

а) назначить гражданина на должность муниципальной службы;

б) отказать гражданину в назначении на должность муниципальной службы;

в) применить к муниципальному служащему меры юридической ответственности;

г) представить материалы проверки в соответствующую комиссию по соблюдению требований к служебному поведению муниципальных служащих и урегулированию конфликта интересов.

24. Материалы проверки хранятся в подразделении (у должностного лица), уполномоченном на осуществление проверки, в течение трех лет со дня ее окончания, после чего передаются в архив.

УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 6 кисәге, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 статьясының 8 кисәге, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында» 2009 елның 21 сентябрендәге 1065 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында» 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы Указы нигезләмәләрен исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында нигезләмәне (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына үзләренең муниципаль хокукый актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка каррарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты **Р.Н.Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 02 февраль
№ ПУ-71

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның «02» февралендәге
ПУ-71 номерлы Указы белән
расланды

Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә белән түбәндәге тикшерүләрне тормышка ашыру тәртибе билгеләнә:

а) муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнгән исемлекләргә кертелгән Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнарның (алга таба – гражданнар) керемнәре турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында хисап вакытына бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

б) муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнгән исемлекләргә кертелгән Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең (алга таба – муниципаль хезмәткәрләр) керемнәре турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында хисап чорына һәм хисап чоры алдыннан килгән ике елга бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

в) Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткә кергәндә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә гражданнар тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең (алга таба – Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә гражданнар тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең) дөреслеген һәм тулылыгын;

г) муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан әлеге пунктчада каралган тикшерүләр уздыруга нигез булып торучы мәгълүмат керүгә кадәрге өч ел дәвамында «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны,

мәнфәгатьләр конфликтын кисәтү һәм җайга салу турында таләпләрнең (алга таба – хезмәт тәртибенә таләпләр) үтәлүен, үз вазыйфаларын башкаруын.

2. Әлеге Нигезләмәнең 1 пунктындагы «в» һәм «г» пунктчаларында каралган тикшерү тиешенчә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең теләсә нинди вазыйфасын биләүне дәгъвалаучыга (алга таба – муниципаль хезмәт вазыйфасы) һәм муниципаль хезмәтнең теләсә нинди вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәргә карата башкарыла.

3. Муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнгән вазыйфалар исемлегендә каралмаган муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрнең һәм әлеге вазыйфалар исемлегендә каралган муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучының керемнәре турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү гражданнар тарафыннан Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә бирелүче белешмәләрне тикшерү өчен әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

4. Әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында каралган тикшерү эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары нигезендә тиешле муниципаль орган кадрлар хезмәтенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау бүлекчәсе (әлеге органның коррупциячел һәм башка төрле хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты) (алга таба – бүлекчә (вазыйфаи зат) тарафыннан уздырыла.

Һәр гражданга яисә муниципаль хезмәткәргә карата аерым карар кабул ителә һәм язма рәвештә рәсмиләштерелә.

5. Әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында каралган тикшерүне уздыру өчен язмача рәвештә түбәндәгеләр тарафыннан бирелгән җитәрлек мәгълүмат нигез булып тора:

а) хокук саклау органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары;

б) муниципаль органнар кадрлар хезмәтенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәләре хезмәткәрләре яисә әлеге органнарның коррупциячел һәм башка төрле хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары;

в) сәяси партияләрнең төбәк яисә җирле бүлекчәләре, шулай ук закон нигезендә теркәлгән, ләкин сәяси партияләр булып тормаган төбәк иҗтимагый берләшмәләре;

г) тиешле муниципаль берәмлектә оештырылган иҗтимагый совет;

д) массакүләм мәгълүмат чаралары.

6. Тикшерү өчен аноним характердагы мәгълүмат нигез була алмый.

7. Тикшерү уздыруга кадәр тикшерү үткәрүгә вәкаләтле бүлекчә (вазыйфаи зат) муниципаль хезмәткәрдән язмача рәвештә аңлатма таләп итәргә тиеш. Әгәр дә ике эш көнендә муниципаль хезмәткәр мондый аңлатма бирмәсә, тиешле акт төзелә. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан аңлатманың бирелмәве тикшерү уздыруга комачаулык итми.

8. Тикшерү, аны уздыру турындагы карар кабул ителеп, 60 көннән дә соңга калмый үткәрелә. Тикшерү вакыты аны уздыру турында карар кабул иткән зат тарафыннан 90 көнгә кадәр озайтылырга мөмкин.

9. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле бүлекчә (вазыйфаи зат) тикшерүне:

а) мөстәкыйль рәвештә;

б) әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында билгеләнгән тәртиптә, оператив-эзләү эшчәнлеге башкаруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнарына «Оператив-эзләү эшчәнлеге турында» 1995 елның 12 августындагы 144-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы өченче өлеше нигезендә сорату җибәрү турында тәкъдим кертү юлы белән уздыра.

10. Әлеге Нигезләмәнең 9 пунктындагы «а» пунктчасында каралган тикшерүне уздырганда тикшерү үткәрүгә вәкаләтле бүлекчә (вазыйфаи зат) түбәндәгеләргә хокуклы:

а) граждан яисә муниципаль хезмәткәр белән әңгәмә уздырырга;

б) керемнәре турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында граждан яисә муниципаль хезмәткәр тарафыннан бирелгән белешмәләрне һәм өстәмә материалларны өйрәнергә;

в) гражданнан яисә муниципаль хезмәткәрдән керемнәре турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында бирелгән белешмәләр һәм материалларга аңлатмалар алырга;

г) билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына, башка федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт органнарына, федераль дәүләт органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга һәм җәмәгать берләшмәләренә (алга таба – дәүләт органнары һәм оешмалары) гражданның яисә муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында; Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә граждан тарафыннан бирелгән белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы турында; муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәве хакында аларда булган белешмәләр турында сорату (оператив-эзләү эшчәнлеген башкаруга яисә аның нәтиҗәләренә кагылган, кредит оешмаларына, Россия Федерациясе салым органнарына, күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәвен тормышка ашыручы органнарга соратулардан тыш) җибәрергә;

д) алар ризалыгы белән физик затлардан белешмәләр һәм мәгълүмат алырга;

е) граждан яисә муниципаль хезмәткәр биргән белешмәләргә Россия Федерациясенең коррупциягә каршы көрәшү турындагы законнары нигезендә анализ уздырырга.

11. Әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «г» пунктчасында каралган соратуда түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) сорату җибәрелә торган дәүләт органы яисә оешмасы җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме;

б) аның нигезендә сорату җибәрелә торган норматив хокукый акт;

в) керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләре тикшерелә торган гражданның яисә муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә тулылыгы һәм дөреслеге тикшерелә торган белешмәләр биргән гражданның яки аның тарафыннан хезмәт тәртибенә талəпләрнең үтәлмәве турында белешмәләр булган муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу вакыты һәм туу урыны, теркәлү, яшәү һәм (яисә) тору урыны, вазыйфасы һәм эш (хезмәт) урыны, шәхесен таныклаучы документның төре һәм реквизитлары;

г) тикшерелергә тиешле белешмәләрнең эчтәлеге һәм күләме;

д) соратып алына торган белешмәләрне тапшыруга бирелгән вакыт;

е) соратуны әзерләгән муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, инициаллары һәм телефон номеры;

ж) салым түләүченең идентификация номеры (Россия Федерациясе салым органнарына сорату җибәргән очракта);

з) кирәк булган башка белешмәләр.

12. Банк, салым сере яисә закон нигезендә саклана торган башка сер булып торган белешмәләр сорату, граждан яисә муниципаль хезмәткәрләргә, аларның ирләре (хатыннары) һәм балигъ булмаган балаларына карата оператив-эзләү чаралары уздыру турында хокук саклау органнарына сорату Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә юллана.

13. Әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында каралган тикшерүне уздырганда, әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән соратулар җибәрү зарурлыгы туса, Татарстан Республикасының тиешле муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы Татарстан Республикасы Президентына тәкъдим кертә. Әлеге тәкъдимгә Татарстан Республикасы Президенты хаты проекты рәвешендәге тиешле сорату проекты теркәлә, анда әлеге Нигезләмәнең 11 пунктында каралган белешмәләр бирелә.

Оператив-эзләү чаралары үткәрү зарурлыгы килеп чыкса, Татарстан Республикасы Президенты хаты проектында шулай ук тикшерү өчен нигез булып торган белешмәләр, соратулар җибәрелгән (җибәрелә торган) дәүләт органнары һәм оешмалары, аларда нинди мәгълүмат соратылуы күрсәтелә, шулай ук «Оператив-эзләү эшчәнлеге турында» 1995 елның 12 августындагы 144-ФЗ номерлы Федераль законның шуларга таянып эш ителгән тиешле нигезләмәләре күрсәтелә.

Әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән соратуларны җибәрү турында тәкъдим тикшерү уздыруга вәкаләтле бүлекчә (вазыйфаи зат) тарафыннан әзерләнә һәм эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасының тиешле муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгына җибәрелә.

14. Сорату алган дәүләт органнары һәм оешмалары җитәкчеләре федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда соратуны үтәүне оештырырга һәм соратылган мәгълүматны бирергә тиеш.

15. Тикшерү уздыруга вәкаләтле бүлекчә (вазыйфаи зат) түбәндәгеләрне тәэмин итә:

а) муниципаль хезмәткәргә аңа карата тикшерү башлану турында язма рәвештә хәбәр итүне һәм әлеге пунктгагы «б» пунктчасының эчтәлеген аңлатуны – тиешле карарны алган көннән соң ике эш көне дәвамында;

б) муниципаль хезмәткәр мөрәҗәгать иткән очракта, аның белән әңгәмә уздыруны, әңгәмә барышында аңа үзенә әлеге Нигезләмә таләпләре нигезендә бирелгән нинди белешмәләре һәм хезмәт тәртибенә нинди таләпләрнең үтәлеше тикшерелергә тиешлеге турында хәбәр ителә – муниципаль хезмәткәр мөрәҗәгать иткән көннән соң җиде эш көне дәвамында, ә нигезле сәбәпләр булганда – муниципаль хезмәткәр белән килешенгән вакытларда.

16. Тикшерү тәмамланганнан соң тикшерү уздыруга вәкаләтле бүлекчә (вазыйфаи зат) Россия Федерациясенең дәүләт сере турында законнарын үтәп, муниципаль хезмәткәрне тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга тиеш.

17. Муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләргә хокуклы:

а) язма рәвештә аңлатмалар бирергә: тикшерү барышында; әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча; тикшерү нәтиҗәләре буенча;

б) өстәмә материаллар бирергә һәм алар буенча язма рәвештә аңлатма бирергә;

в) тикшерү уздыруга вәкаләтле бүлекчәгә (вазыйфаи затка) әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча аның белән әңгәмә үткәрү турында канәгатьләндерелергә тиешле үтенечнамә бирәп мөрәҗәгать итәргә.

18. Әлеге Нигезләмәнең 17 пунктында күрсәтелгән аңлатмалар тикшерү материалларына теркәп куела.

19. Тикшерү уздыру чорында муниципаль хезмәткәр аны үткәрү турында карар кабул ителгән көннән соң 60 көннән дә артмаган вакытка муниципаль хезмәттә биләгән вазыйфасыннан читләштерелергә мөмкин. Тикшерү үткәрү турында карар кабул иткән зат тарафыннан читләштерү вакыты 90 көнгә кадәр озайтылырга мөмкин.

Муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттә биләгән вазыйфасыннан читләштерү чорында аңа биләгән вазыйфасына каралган хезмәт хакын түләү туктатылмый.

20. Тикшерү уздыруга вәкаләтле бүлекчә (вазыйфаи зат) эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә тикшерү нәтиҗәләре турында доклад тапшыра. Әлеге докладта түбәндәге тәкъдимнәрнең берсе булырга тиеш:

а) гражданны муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләү турында;

б) гражданны муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләүдән баш тарту турында;

в) муниципаль хезмәткәргә карата юридик җаваплылык чараларын куллану өчен нигезләр булмавы турында;

г) муниципаль хезмәткәргә карата юридик җаваплылык чараларын куллану турында;

д) тикшерү материалларын тиешле муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиягә җибәрү турында.

21. Тикшерүне уздыру нәтиҗәләре турындагы белешмәләр, шәхси белешмәләр һәм дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнарын үтәп, аны үткәрү турында карар кабул иткән затның язма ризалыгын алып, тикшерү уздыруга вәкаләтле бүлекчә (вазыйфаи зат) тарафыннан, бер үк вакытта бу хакта үзенә карата тикшерү уздырылган гражданга яисә муниципаль хезмәткәргә хәбәр итеп, хокук саклау органнарына, башка дәүләт һәм җирле үзидарә органнарына һәм аларның вазыйфаи затларына, сәяси партияләрнең даими эшләп килә торган төбәк һәм җирле бүлекчәләренә, закон нигезендә теркәлгән, ләкин сәяси партияләр булып тормаган башка төбәк җәмәгать берләшмәләренә, тикшерүне уздыру өчен нигез булып торган мәгълүмат биргән тиешле муниципаль берәмлектә оештырылган иҗтимагый советка тапшырыла.

22. Тикшерү барышында җинаять яисә административ хокук бозу билгеләре булу турында таныклаучы хәлләр ачыкланганда, бу хактагы материаллар дәүләт органнарына аларның компетенциясе нигезендә бирелә.

23. Гражданны муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләргә вәкаләтле булган яисә муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәткә билгеләп куйган вазыйфаи зат, докладны һәм әлеге Нигезләмәнең 20 пунктында күрсәтелгән тиешле тәкъдимне караганнан соң, түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданны муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләргә;

б) гражданны муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләүдән баш тартырга;

в) муниципаль хезмәткәргә карата юридик җаваплылык чараларын кулланырга;

г) тикшерү материалларын муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссиягә җибәрергә.

24. Тикшерү материаллары тикшерү тәмамланганнан соң өч ел дәвамында тикшерү уздыруга вәкаләтле бүлекчәдә (вазыйфаи затта) саклана, аннары архивка тапшырыла.